**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «22» апреленнән № 198

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы администрациясе Башлыгының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының звеносы турында» 2005 елның 28 мартындагы, 33 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәллэрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юк итү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы Карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы администрациясе Башлыгының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының звеносы турында» 2005 елның 28 мартындагы, 33 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында htt://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче в.б. Л.К. Исхакова